

Матди булмаган кыйммәтләрне саклау, арттыру һәм киләчәк буыннарга тапшыру мөһим һәм җаваплы миссия.
Бу олкәдә Саранск шәһәрендә Н.П.Огарев университеты бинасында «Тәрбиянен яна фәлсәфәсе» балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм vзара хезмәттәшлек буенча директор кинәшчеләренен Респуб-лика форумы узды. Форум эшендә балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләv, тәрбияләv буенча Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбенен директор кинәшчесе Сабина Руслан кызы Макунина әлеге чарада һәм Саранск шәһәренен 15 нче номерлы мәгариф vзәгендә Педагог һәм Остаз елын ябу тантанасында катнашты. Форумда катнашучыларны Мордовия Главасы Артём Алексеевич Здунов һәм видеоформатта РФ мәгариф министры Сергей Кравцов котлады. Чара ахырында барлык педагоглар һәм остазлар очен концерт узды.
Татар Пешлә гомуми урта белем бирv мәктәбе директоры кинәшчесе, мәктәп психологы, 7 класс укучыларынын сыйныф җитәкчесе Сабина Руслан кызы Макунина, чара кысаларында vткән медиаvзәк һәм медиагруппа эшен оештыру буенча группа эшендә катнашып, чыгыш та ясады.
Мәктәптә директор кинәшчесе булу җаваплы эш. Конекә берничә чара vткәрv хезмәттә мобиль булуны сорый. Мәсәлән, әле генә «Навигаторы детства» белән



«Движение Первых» кысаларында Блокадалы Ленинградньн 80 еллыгын билгеләv буенча чаралар комплексын барлык сыйныфларда vткәрvне, укучылар белән профилактик чаралар буенча полиция хезмәткәре сойләшvне (25 гыйнварында Россия Эчке эшләр министрлыгынын Рузаевка элемтәләр буенча юнәлеш инспекторы Диана Марат кызы Багапова 5 сыйныф укучыларына гомумән транспорт полициясендә хезмәт итv, эшнен топ юнәлешләре һәм транспорт полициясе хезмәткәрләре алдында торган бурычлар турында, олкән сыйныфлыларына - профориентация турында сойләде) оештыру, кар кvпләп яуган вакытны Татар Пешлә авылы һәйкәле янын, олыларга кар («Время добрых дел») чистартырга булышу, Гаилә елына (онлайн фотокvргәзмә) старт алуны башлап җибәрv һәм башкаларын дорес оештырып сыйныф җитәкчеләре белән бергәләп vткәрәләр - киләчәк буынга тиешле тәрбия бирv остендә эшлиләр. Матди булмаган кыйммәтләрне саклау, арттыру һәм киләчәк буыннарга тапшыру мөһим һәм җаваплы миссияне тормышка ашыралар. Оештырылган чараларны Сабина Руслан кызы укытучылар һәм укучылар белән бергәләп эшләргә тырыша. Сабинанын исеме Мордовия халкына мәктәптә укыган чакта торле-торле конкурсларда актив катнашып җинvләр яулаган вакытта билгеле булды. Шул исәптән, татар теле һәм татар әдәбияты олимпиадаларында да. Ул бит vзе дә Татар Пешлә авылында туып vскән, шул мәктәптә белем алган, эшли һәм бvген туган ягы очен җан атып яши.

**Наилә НАСЫРОВА**